СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**22.05.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 191**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында

2003 елның 6 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару турында» Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы президиумының 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы карарын исәпкә алып, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль районы Уставына таянып , норматив хокукый базаны камилләштерү, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру, аларның эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып баруга вәкаләтле вәкил итеп Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеген (алга таба - юридик бүлек) билгеләргә.

3. Әлеге леге карарның 1 пунктында расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән җирле үзидарә органнарына һәм аларның вәкаләтле бүлекчәсенә:

1) 2017 елның 01 июненә кадәр муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын төзергә һәм аларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтына урнаштырырга;

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-191 22.05.2017 Башкаручы: Майорова Е.А.
11 1биттән. Бит булдырылган: 23.05.2017 09:59
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

2) муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруны һәм аларны Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында актуаль хәлдә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын актуаль хәлдә тоту, шулай ук законнарга туры килми торган муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану, аларны үз көчләрен югалткан дип тануны тәэмин итү, эш башкаруга һәм документлар әйләнешенә җаваплы хезмәткәрләргә (затларга) муниципаль норматив хокукый актларга карата кергән мәгълүматны юридик бүлеккә тапшыруны (массакүләм мәгълүмат чараларында, суд актларында, контроль яисә күзәтчелек органнары актларында, хокукый экспертиза бәяләмәләрендә бастырып чыгару турында) тапшырырга, кергән көнне йә, күрсәтелгән срокта тапшырылмаган очракта, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2017
елның 22 маендагы 191
номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә, реестрлар, җирле үзидарә органнары) норматив хокукый базасын камилләштерү, җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларны һәм алар турындагы мәгълүматларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру, муниципалитетлар эшчәнлеге турында мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2009 елның 9 февралендәге«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

1.2. Реестрлар муниципаль хокукый актларның гомуми реестрлары белән бер үк вакытта (параллель рәвештә), алар җирле үзидарә органының норматив һәм норматив булмаган характердагы актлары(хокукны куллану актлары) буенча эш белән идарә итү һәм документлар әйләнешен алып баручы бүлекчәләре һәм исәпкә алу хезмәткәрләре тарафыннан алып барыла һәм аларны тулысынча яки өлешчә алмаштырмый. Реестрлар муниципаль норматив хокукый актларны теркәү максатларында эшләнми.

1.3. Реестрлар түбәндәге бурычларны хәл итү өчен алып барыла:

норматив характердагы муниципаль хокукый актларны, алар турында белешмәләрне исәпкә алу, аларның законнарга туры килүен тикшереп тору;

коррупциягә каршы экспертизаны вакытында үткәрү һәм муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгаруны, актларны һәм алар турындагы мәгълүматларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына законнарда билгеләнгән очракларда вакытында җибәрүне контрольдә тоту;

вәкиллекле орган, муниципаль берәмлек башлыгы, башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм аппаратлары эшчәнлеген оператив мәгълүмат бирү һәм белешмә белән тәэмин итү;

гражданнарның һәм юридик затларның, шул исәптән хуҗалык итүче субъектларның, иҗтимагый һәм башка кызыксынган оешмаларның, массакүләм мәгълүмат чараларының, контроль (күзәтчелек) органнарының һәм башкаларның муниципалитетның норматив хокукый базасына керүен тәэмин итү.

1.4. Реестр-җирле үзидарә органының барлык муниципаль норматив хокукый актлары турында мәгълүматны Нигезләмәнең 2 бүлегендә билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә, һәркемгә ачык итеп (махсус программа тәэминаты кулланмыйча мәгълүматны чагылдырырга мөмкинлек бирүче таблица форматында) рәсмиләштерелгән мәгълүмат базасы.

1.5. Җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруга Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге (алга таба – юридик бүлек) вәкаләтле булып тора.

1.6. Муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла торган реестрларның компьютер (цифрлы) версияләрен алып бару өчен җаваплы булып, билгеләнгән тәртиптә Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән органнар (затлар) белән хезмәттәшлек итүче Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге (алга таба - җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге ) җаваплы булып тора.

## 2. Реестрларны формалаштыру һәм алып бару

2.1. Реестрлар рус телендә электрон рәвештә алып барыла.

2.2. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге белешмәләр кертелә:

бастырып чыгарылганнары да, басылып чыкмаганнары да; гамәлдә булганнары да, көчләрен югалтканнары яисә башка актлар белән үзгәртелгәннәре дә;

башка актларга үзгәрешләр кертү яисә көчләрне югалту турында, башка актларның гамәлдә булу срокларын туктатып тору яисә озайту турында.

2.3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратында алып барыла торган реестрларга (1, № 2 нче кушымталар) түбәндәге белешмәләр кертелә:

Зеленодольск муниципаль районы Советы кабул иткән карарлар турында;

җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар турында.

2.4. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының реестрына (3 нче кушымта) түбәндәге белешмәләр кертелә:

норматив характердагы карарлар турында;

норматив характердагы күрсәтмәләр турында (норматив характерга ия булган аерым нигезләмәләре булган).

2.5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетында алып барыла торган реестрга (4 нче кушымта) түбәндәге белешмәләр кертелә:

норматив характердагы карарлар турында;

норматив характердагы күрсәтмәләр турында (норматив характерга ия булган аерым нигезләмәләре булган).

2.6. Реестрга түбәндәге белешмәләр кертелә: хокукый акт төре (хокукый актларның һәр төре буенча аерым исемлек алып барырга тәкъдим ителә);

кабул итү датасы;

теркәү номеры (эш башкаруны һәм документлар әйләнешен алып бара торган бүлекчәсе тарафыннан муниципаль хокукый актларның тиешле реестрында билгеләнгән);

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-191 22.05.2017 Башкаручы: Майорова Е.А.
11 4биттән. Бит булдырылган: 23.05.2017 09:59
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

исеме (булган очракта).

2.7. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында түбәндәге өстәмә белешмәләр кертелергә тиеш:

бастырып чыгару (халыкка җиткерү) турында;

үзгәрешләр кертү (көчләрен югалту), суд тарафыннан гамәлдә түгел дип тану турында.

2.7.1. Реестрга муниципаль норматив хокукый актлар турында башка өстәмә мәгълүмат кертелергә мөмкин.

2.8. Муниципаль норматив хокукый актлар турында мәгълүмат реестрларда актлар кабул ителгән (нәшер ителгән) көненә карап хронологик тәртиптә урнаштырыла.

2.9. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре эш башкару һәм документлар әйләнеше буенча җаваплы булган буйсынган бүлекчәләргә (затларга) яисә Нигезләмәнең 1.5 пунктында күрсәтелгән затларга Нигезләмәнең 2.6, 2.7 пунктларында каралган мәгълүматны кабул итү (формалаштыру) көнендә яки, күрсәтелгән срокка тапшыру мөмкин булмаган очракта, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшыруны тәэмин итәргә йөклиләр.

Реестрларга яңа кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актлар текстлары (яки элек реестрга кертелмәгән хокукый база мониторингы нәтиҗәсендә ачыкланган актлар) кушымта итеп бирелә.

2.10. Юридик бүлек Нигезләмәнең 2.9 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны эшкәртә һәм реестрга кертә, шулай ук аны, кушымта итеп бирелгән муниципаль норматив хокукый актлар текстлары белән бергә, җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, җибәрә.

Үзгәрешләр кертелә торган актлар кергәндә, 7 эш көне эчендә Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштыру өчен, үзгәрә торган муниципаль норматив хокукый актларның актуаль редакцияләре төзелә һәм җибәрелә.

2.11. Җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге реестрның актуаль редакциясен һәм Нигезләмәнең 2.9 пунктының икенче абзацында, 2.10 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән актлар текстларын Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында, кергән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, урнаштыра.

Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтының җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган бүлекләрендә реестрлар тиешле җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары исемлегенең беренче файллары буларак урнаштырыла.

Муниципаль норматив хокукый актларның текстлары Нигезләмәнең 2.8 пунктында билгеләнгән реестрларда алар турында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә туры килгән тәртиптә урнаштырыла.

Үзгәртелә торган муниципаль норматив хокукый актларның актуаль редакцияләре, аларга үзгәрешләр кертүче актлардан соң урнаштырыла.

2.12. 2.9 пунктының икенче абзацында, 2.10 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актлар текстлары, әгәр алар дәүләт серен (конфиденциаль характердагы башка белешмәләрне) тәшкил итсәләр, Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырылырга тиеш түгел. Мондый актлар турындагы мәгълүмат аларның эчтәлеген ачарга мөмкинлек бирми торган өлешләргә кертелергә мөмкин.

## 3. Реестрларда булган мәгълүматны бирү тәртибе һәм шартлары. Мәгълүмат элемтәсенең башка мәсьәләләре

3.1. Реестрларда булган мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырыла торган һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булып тора. Аны кызыксынучылар тарафыннан электрон рәсемнәр (файллар) рәвешендә алу чикләнми.

3.2. Законнарда каралган очракларда реестрларда булган һәм вәкаләтле органнарга тапшырылырга тиешле мәгълүматларны тапшыру (бирү) тиешле норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3. 2015 елның 3 ноябрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җаваплы затлар күрсәтелгән белешмәләрне җыйган өчен муниципаль районга керүче җирлекләрдән тиешле реестрлар алып баруны тәэмин итү максатларында, муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген (килешү буенча) оештыралар.

## 4. Реестрлар алып бару тәртибен бозган өчен җаваплылык

4.1. Нигезләмәнең 1.5, 1.6 пунктларында күрсәтелгән җитәкчеләр һәм башка вәкаләтле затлар Нигезләмәдә билгеләнгән реестрларны алып бару тәртибен бозган өчен дисциплинар җаваплылык тоталар.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының

муниципаль норматив хокукый актлары (карарлар)

**РЕЕСТРЫ**

| № п/п | Кабул итү датасы | № акты | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| **20 ел** | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| **20 ел** | | | | | |
| | | | | | |
| **20 ел** | | | | | |
| | | | | | |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирле референдумнарда кабул ителгән карарларның муниципаль норматив хокукый актлары рәвешендә рәсмиләштерелгән

**РЕЕСТРЫ**

| № п/п | Кабул итү датасы | № акты | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **20 ел** | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | **20 ел** | | |
| | | | | | |
| | | | **20 ел** | | |
| | | | | | |

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-191 22.05.2017 Башкаручы: Майорова Е.А.
11 8биттән. Бит булдырылган: 23.05.2017 09:59
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башлыгының
муниципаль норматив хокукый актлары

**РЕЕСТРЫ**

| № п/п | Кабул итү датасы | № акт ы | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| **20__ ел** | | | | | |
| **Карар** | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | |
| | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | |
| **Карар** | | | | | |
| | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | |
| | | | | | |
| **20__ ел** | | | | | |
| **Карар** | | | | | |
| | | | | | |
| **Күрсәтмәләр** | | | | | |
| | | | | | |

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-191 22.05.2017 Башкаручы: Майорова Е.А.
11 9биттән. Бит булдырылган: 23.05.2017 09:59

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актлары
**РЕЕСТРЫ**

| № п/п | Кабул итү датасы | № акты | Акт исеме | Рәсми басылып чыгу (халыкка җиткерү) чыганагы һәм датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **20__ ел** | | |
| | | | **Карар** | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | **Күрсәтмәләр** | | |
| | | | | | |
| | | | **20__ ел** | | |
| | | | **Карар** | | |
| | | | | | |
| | | | **Күрсәтмәләр** | | |
| | | | | | |
| | | | **20__ ел** | | |
| | | | **Карар** | | |
| | | | | | |
| | | | **Күрсәтмәләр** | | |
| | | | | | |

Документ электрон формада булдырылган. № 01-01-05-191 22.05.2017 Башкаручы: Майорова Е.А.
11 10биттән. Бит булдырылган: 23.05.2017 09:59
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН